**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫСОВЕТЫ**

422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, Сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарнлы Матак авылы

2024 елның 16нчы декабре 309№

Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003нче елның 6нчы октябренең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль закон нигезендә (соңгы үзгәрешләр белән), 2004нчы елның 28нче июленең «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45нче номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Әлки районы Прокуратурасының хокук иҗат итү инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 маддәләре нигезендә Әлки муниципаль районы Советы карар кабул итте: :

1. Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"гы карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. "Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"гы карарны, Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы маддәләренең яңа редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Әлки муниципаль районының http://alkeevskiy.tatarstan.ru.рәсми сайтында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советы Рәисе урынбасарына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль
районы Башлыгы А.Ф.Никошин

2024нче елның 16нчы
декабрендәге Татарстан
Республикасы
“Әлки муниципаль районы”
муниципаль берәмлегенең
309нчы№ карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегеннең Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

6 маддәдәге ("Муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре"):

32 пунктның 1 өлешнең яңа редакциядә бәян итәргә:

"27) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;"

1 өлешнең 33 пунктында ", шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән"сүзләрен өстәргә.;

9 маддәдә ("Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү"):

2 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарә органнары бу максатларга муниципаль берәмлекләргә бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы.»;

10 маддәдә («районның муниципаль хезмәттәшлектә катнашуы»):

10 маддәные  яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлки муниципаль районында муниципальара хезмәттәшлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла»;

20.1 маддәдә («Авыл торак пункты старостасы»):

20.1 маддәнең 5 пунктындагы 2 абзацында "1-7 пунктларында" сүзләрен "1-7 һәм 9.2 пунктларында"сүзләренә алмаштырырга.;

31 маддәдә ("Район Советы депутаты статусы"):

31 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктны өстәргә:

9. 1) анның чит ил агенты статусын алуы;

34 маддәдә ("Район Советы компетенциясе"):

1 пунктның 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«26. муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;

48 маддәдә ("Башкарма комитет вәкаләтләре"):

1 пунктның 7 пунктчасындагы 9 абзацта «, шулай ук рекреация максатларында су объектларыннан файдалану кагыйдәләреннән»сүзләрен өстәргә.;

1 пунктның 6 пунктчасындагы 7 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, Әлки муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

81 маддәдә ("Районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү"»

Түбәндәге эчтәлекле 4 өлешне өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.»